РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАМАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423643, РТ, Менделеевский район,
с.Камаево, ул. Дифгата Сирая д.29А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАМАЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423643 , РТ, Менделеевск районы,
Камай авылы, Дифгать Сирай урамы
29А йорты

Тел./ факс: 8(85549) 3-55-33, E-mail: Kam.Men@tatar.ru

РЕШЕНИЕ — КАРАР

02. 03 2023 ел — № 78

"Җир салымы турында"
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге
Советының 2020 елның 24 мартындагы
149 номерлы карарына үзгәрешләр
кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Камай авыл җирлеге советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Җир салымы турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге советының 2020 елның 27 февралендәге 149 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 5 пунктын үзгәртергә һәм бәян итәргә: «салым түләүчеләргә – оешмаларга салым түләүнең агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталы узганнан соң җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасы ¼ күләмендә алдан түләнүен билгеләү, узган хисап чорыннан соң килүче айның 28 числосыннан да соңга калмыйча. Салым чоры нәтиҗәләре буенча түләнергә тиешле салым суммасы үткән салым чоры артыннан килүче елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә».

Салым физик затлар - салым түләүчеләр тарафыннан узган салым чорыннан соң килүче елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча түләнергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Камай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларга урнаштырып игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый

мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://mendeleevsk.tatarstan.ru) « Камай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны финанс-бюджет мәсьәләләре буенча даими комитетка йөкләргә.

Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге
Советы рәисе урынбасары                                        Р.Р. Калимуллин.